**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 14. 10. 2019

КАРАР
№ ПР-225

Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү административ регламентларны раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” 2010 елның 2 ноябрендәге № 880 санлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә**:

1. Расларга:

1.1. Архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклаучы архив фондлары буенча архив документлары күчермәләрен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (1 нче кушымта).

1.2. Муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга дәүләт милкенә кертелгән һәм муниципаль архивта саклаучы архив документларын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (2 нче кушымта).

1.3. Дәүләт милкенә кертелгән архив документларының урнашу мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (3 нче кушымта).

2.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Архив эше өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2013 ел, 9 апрель, ПР-259 нчы санлы карарын үз көчен югалткан дип санау хакында.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru. үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Л. Ф. Нурлыева